# ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ТЕЛӘЧЕ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ СОВЕТЫ
**(III чакырылыш)**

кырыгынчы утырыш
**КАРАРЫ**

3 сентябрь 2020 ел **№ 251** Теләче авылы

Теләче муниципаль районы Советының
2014 елның 20 февралендәге 192 номерлы
«Теләче муниципаль районы «Теләче»
сәнәгать (индустриаль) парка территориясендә
үзләренә арендага бирелгән җир кишәрлекләре
өчен аренда түләвеннән үз эшчәнлеген гамәлгә
ашыручы оешмаларны азат итү турында» карарына
үзгәрешләр кертү хакында

ҖЧҖ "Созидание" идарәче компаниясе генераль директорының 2020 елның 1 сентябрендәге хатын карап, Россия Федерациясе Җир кодексы, «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә, Теләче муниципаль районы Советы **карар итте:**

1.Теләче муниципаль районы Советының 2014 елның 20 февралендәге 192 номерлы «Теләче муниципаль районы «Теләче» сәнәгать (индустриаль) парки территориясендә үзләренә арендага бирелгән җир кишәрлекләре өчен аренда түләвеннән үз эшчәнлеген гамәлгә ашыручы оешмаларны азат итү турында» карарының (район Советының 2015 елның 20 маендагы 266 номерлы, 2018 елның 1 февралендәге 120 номерлы карары редакциясендә) 1 пунктына, түбәндәге редакциядә бәян итеп, үзгәреш кертергә:

1.1. «1. 2013 елның 1 маеннан 2021 елның 31 декабренә кадәр Татарстан Республикасы Теләче муниципаль районы чикләрендә «Теләче» сәнәгать паркы территориясендә урнашкан , Теләче авыл җирлеге, Теләче муниципаль районы муниципаль милкендә булган яки дәүләт милке чикләнмәгән җирләрне арендага алу түләвеннән азат итәргә,арендага җир кишәрлекләре бирелгән Теләче муниципаль районы бюджетына күчерү өлешендә, түбәндәге категорияләрдәге юридик затлар өчен:

- үзенең җитештерү эшчәнлеген «Теләче» сәнәгать паркы территориясендә башкаручылар;
- «Теләче» сәнәгать парки территориясендә продукция җитештерү өчен корылмалар, объектлар төзү эшләрен башкаручылар.».

2.Әлеге карар гамәлдәге законнар нигезендә үз көченә керә.

Теләче муниципаль районы
Башлыгы урынбасары А.Г. Фәтхуллин